**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлеге Бура-Киртә торак пунктында гражданнар җыены карары**

20.11.2020 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең Бура-Киртә торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Пәнәче авыл җирлегенең Бура-Киртә авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2021 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
- 4 данә мәгълүмат тактасы сатып алу;
- елга аша техника белән чыгу юлын ремонтлау;
- зираттагы агач үсентеләрен бетерү;
- юлны ремонтлау;
- комплекты белән янгын сүндерү колонкасы сатып алу.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгы** **М.Х.Туктаров**